Башҡортостан Республикасы Мәгариф Министрлыгы
балаларга өстәмә белем бирү муниципаль бюджет
учреждениясы Уфа районы балалар иҗат йорты

# Тикшеренү эше

## *“Аулак йорт”*

Эшне башҡарды:

«Дуслык» фольклор студиясы.

Җитәкчесе:

Ғиндуллина Гөлфинә Нуррахман кызы
югары квалификациялы педагог.

Уфа -2016

## Әчтәләге

**Кереш**

**Халкыбыз уеннары.**

**Башкорт халык йоласы “Аулак өй”**

**Аулак өйләрдә уйналган  уеннар.**

**Йомгаклау**

**Файдаланылган әдәбият**

## Кереш

Башкорт халкының да, башка милләтләрнеке шикелле үк, бай уен репертуары һәм уен фольклоры бар.

Уеннарның эчтәлегенә күз салсаң, аларның тормыш-көнкүрешнең һәм хезмәт төрләренең бер чагылышы икәнлегенә ышанасың. “Үзеннән-үзе аңлашыла, – дип яза үзенең бер хезмәтендә Г.В.Плеханов, – вакыт ягыннан алданрак торган, теге яки бу төрдәге җитди шөгыль юралышы булмаган бер генә уен формасы да юк”. Чынлап та, көнкүрештә берәр эш-шөгыльне яки йоланы үтәү, күмәк эшнең тәртибен билгеләү өчен уйнала торган уеннар байтак.

Уеннарны “балалар һәм өлкәннәр уены” дип аерып куйсак та, ул аеру шартлы рәвештә генә эшләнә. Чынлыкта, уеннарның табигый яшәешендә бу чикне сызу шактый кыен мәсьәлә. Әмма шулай да яшьләр һәм олылар тарафыннан уйнала тоган уеннар эчтәлекләре белән беркадәр аерылып тора. Зурлар уеннары күңел ачу, җорлану гына түгел, ә еш кына йолалык мәгънәсенә ия була яки үз парыңны эзләү, яраткан кешең белән күрешү, кавышу чарасы да булып тора. Кыскасы, зурларның уеннары тормыш-көнкүреш, кеше яшәеше белән тыгызрак бәйләнгән.

Халык уеннары милләтнең профессиональ мәдәнияте һәм сәнгате барлыкка килүдә нигез вазыйфасын үтәгәннәр. Әйтик, ,башкортларның профессиональ бию, җыр, театр сәнгатенең электән үк шактый югары күтәрелүенең бу сәнгать төрләренең халыктагы тамырлары нык булудан дип әйтә алабыз. Тамашалы милли сәнгать төрләренең нигезендә халык уеннары ята.

Һәр йола уеннарының үзенең төгәл үткәрү вакыты бар.Кыш көне кич утырулар, аулак өйләр булса, яздан алып көннәр салкынайтканчы, көз аена кадәр, яшьләр кичләрен капка төпләрендә,авыл читендә, акланнарда,су буенда, һ.б. ураннарда күңел ача. Һәрбер авылның үз кичке уен урыны һәм аның исеме була.

Кичке уеннарда кулланышка керә торган күңел ачуларда башлыча җырлы-биюле, түгәрәк уеннары, ә балаларда хәрәкәтле уеннар төп урынны алып тора.

Уеннарның борын замандарда уқ барлыкка килүе билгеле. Халык аларны югалтмыйча, заманына күрә мәгънәләрен, функцияларын үзгәртеп ныгытты, үстерде һәм бугенге көнгәчә китереп җиткерде.

Күзәтүләр буенча 1950 елларга тиклем балалар уеннарның бөтен төрләре дә популяр иде.Соңгы 20-30 йыл әчендә кайсы бер үзгәрешләр күзәтелде. Мәсәлән, бу чорда җырлы-биюле уеннарыбызның саны кимеде һәм шулай ук драмалы уеннар да сирәгерәк уйнала башланды. Гомүмән, хәзер халык уеннарының актив кулланыштан китүе ачык күренә. Әгәр дә без, киләчәк буыннарны милли традицияларда тәрбияләү зарурлыгын югалтмыйк дисәк, халык рухының аерылгысыз бер өлешен тәшкил иткән уеннарыбызны югалтуга юл куймаска тиешбез.

**Максат.**

Халык уеннарын өйрәну.

**Бурычлар.**

1.Тема буенча әдәбият уку.

2. “Аулак өйләр”дә кулланылган уеннарны барлау.

3. Тема буенча презентация үткәрү.

4. Тикшерү эше буенча сценарий төзеп “Аулак өй” йоласын сәхнәгә кую.

**Төп тикшерү предметы.**

“Аулак өй”ләрдә кулланылган халык уеннары.

**Тикшерү методлары.**

- Халык бәйрәмнәре, йолалары, уеннары турында хезмәтләр,әдәбият уку,өйрәнү, анализлау.
- Олы яшьтәге авыл кешеләре, балалар белән әнгәмә оештыру.
- Тема буенча фольклор чыгышларын күзәтү.

**Практикада кулланышы.**

Фольклор түгәрәкләрендә, башкорт теле дәресләрендә, класстан тыш чараларда,сәхнәләрдә һәм балалар бакчаларында тәрбиячеләр өчен

# Башкорт халык йоласы “Аулак өй”

**Очраштыра, таныштыра,**
**Кавыштыра аулак өй.**
**Аулак өйдән китмәс егет,**
**Үзенә яр сайламый.**

Әүвәлге заманнарда татар, башкорт яшьләренең җыелып күңел ача торган урыннары – **аулак өйләр.**



Аулак өй – халкыбызның борынгыдан килгән йоласы, яшьләр өчен аралашу, сөйләшү, киңәшү, танышу урыны булган.

Әйтергә кирәк, аулак өйләргә җыелып күңел ачу күп урыннарда 1950 елларга кадәр дәвам итеп килде. Табигый ки, яшьләр генә катнашкан бу традицион күңел ачуларның һәм андагы уеннарның тотрыклы бер тематик юнәлеше бар: анда үзеңә пар сайлау, яшьләр җәмәгате алдында үзеңнең уңганлыгыңны-булганлыгыңны, зирәклегеңне күрсәтү төп урынны алып тора.

Гадәттә, кызның әти-әнисе күрше авылга кунакка киткәндә, ул алардан кызлар чакырып өчен рөхсәт сорап калган. Хуҗалар киткәннән соң, кызлар кул эшләрен алып, шушы йортка җыелганнар. Алар җырлап, биеп, мәзәкләр сөйләп чигү чиккәннәр, бәйләгәннәр. Бу хәбәрне ишетеп, авыл егетләре гармуннар белән әлеге өйгә килгәннәр. Ишек шакып, ишек аркылы кызлар белән капма-каршы әйтешкән сүзләре кызыклы һәм бүгенге көнгә кадәр сакланып калганнар. Мәсәлән: Егетләрнең "кызлар ишек ачыгыз инде"- дигән сүзләренә каршы, кызлар "ач булсагыз туеп керегез, атаказыгызны суеп керегез"-дип җаваплаганнар.



Кызлар уены "Аулак өй" Башкортостанның төрле төбәкләрендә төрлечә үткән. Кайбер көнъяк - көнчыгыш якларда кызлар үзләре белән пешеренер өчен азык та, кул эшләрен дә алмаганнар. Күңел ачыр һәм уйнар өчен җыелганнар. Ә төньяк-көнчыгыш районнарда киресенчә, төрле азык-түлек җыеп урнаш пешергәннәр. Бераз уйнап- көлеп алганнан соң өстәл корып ашый торган булганнар. Шунысы кызык һәр "Аулак өй"гә килгән кеше үзе белән йолкынган этәч-чебеш алып килергә тиеш булган. Кайбер мәгълүмәтләр буенча чебешсез "Аулак өй"гә кертмәгәннәр. "Аулак өй" не уйнау вакыты да төрлечә булган.

Кайбер авылларда ике-өч сәгатъ уйнаганнар да таралышканнар. Ә кайбер урыннарда таң әтәчләре кычкырганчы уйнаганнар. Ата-аналары озакка киткән вакытларда куна да кала торган булганнар.  Берәүләр йоклап ятканда, икенчеләре иптәшләрен кызык итеп,битләрен корым белән буяу, кызларының толымнарына төрле әйберләр бәйләү кебек кызык-мызыклар уйлап тапканнар. Иртән торып көлешү, гаепле кешене эзләү үзе бер мавыктыргыч күренеш саналган  аулак өйләрдә.

# Аулак өйләрдә уйналган  уеннар.

Аулак өйләр һәрчак уен-көлке, җыр-бию белән гөрләп торган. Анда егетләрнең тапкырлыгы, кызларның матурлыгы макталган. Ә аулак өйләрдә уйнала торган уеннарның иң киң таралганы:  йөзек салыш, күз бәйләш яки сукыр тәкәле, җәза биреш.

***Иске уен, кызык уен –***
***“Йөзек салыш” уены.***
***Уч төбеңә йөзек салам –***
***Аңларсыңмы уемны?***
***Кемдә йөзек сикереп чык.***

**Йөзек салыш уены.**

Яшьләр тезелешеп утыралар, берәү “Йөзек салучы” була. Ул кулларын тотып утырган кешеләрнең барысына да “йөзек салып” чыга. Йөзекнең кемгә туры килүен берсе дә сизмәскә тиеш. Аннан  соң, үзе бер кырыйга китеп, “Кемдә йөзек,сикереп чык”, – ди. Йөзекле кеше сикереп торганда, ике як күршесенең берсе тотып кала алса, йөзекле  кешегә җәза бирелә, тота алмасалар, сикереп торган кеше йөзек салуны яңадан башлый. Уен шул рәвешле дәвам итә.

**Сукыр тәкәле уены.**

Бу уенда шунысы кызык саналган; әгәр дә егет кешенең күзен бәйләп сукыр тәкә итеп калдырсалар, баз авызын ачып, базга мендәр, юрган ыргытып, палас белән каплап куйганнар.Шуңа күрә дә егетләр гел стена буйлап йөрергә тырышканнар. Уйнаучылар төрле юллар белән, сукыр тәкәне баз авызына китерергә тырышканнар. Ә төшеп киткән очракта рәхәтләнеп көлешкәннәр.

**Җәза биреш уеннары:**

**Шешә тәгәрәтү**

Уенчылар түгәрәк уртасында шешә тәгәрәтә. Шешә авызы кемгә карап туктаса, шул кешегә җәза бирәләр. Җыр бию, дисеңме, берәр әбинең мунчасыннан мунча ташы алып килү, йөзгә кадәр йолдыз санау,әтәч булып кычкыру, карт кеше булып кылану,мәзәкләр сөйләү һәм башкалар.



Аулакка килгән яңа кызны, я булмаса егетне кызык итү кебек уеннар бигрәк тә мавыктыргыч саналган. Шундыйлардан:

**Бишмәт җиңе аша түшәм санау.**



Уен өйдә уйнала. Бу уен белән таныш булмаган бер кешедән: “Җиң аша түшәм саный аласыңмы?” – дип сорыйлар. Теге, әлбәттә, батырланып: “Саный алам”, – ди. Шуннан соң аны идәнгә яткыралар да, җиңен йөз тирәсенә туры китереп, пальтосы белән ябалар һәм, ике куллап җиңен торба кебек итеп тотып, шуның аша түшәмне санарга кушалар. Ул чынлап торып түшәм санап азапланган арада берсе пальто җиңеннән су салып җибәрә. Шуннан соң түшәм санаучыдан: “Ничә булды соң түшәм?” – дип шаяртып көләләр.

**Бер күзне йомып  энә саплау.**

Шулай ук, бер күзеңне йомып энә саплый аласыңмы дип сорыйлар. Яңа килгән егеттән яки кыздан. Билгеле ул каршы килми. Ул энә саплаганда икенче берәү корымлы кулы белән күзен тотып тора. Саплап беткәч,  тегенең корым буялган күзен күреп, яшьләр рәхәтләнеп көлешәләр.

“Каеш сугышлы”, “Кем суктылы”, Бер- ике- өчле” , “Яулык сугышлы” уеннары Бүздәк, Илеш, Чакмагыш, Дүртөйле районнарында аулак өйләрнең иң папуляр уеннарыннан саналган.



**Кем суктылы уены.**



**Яулык сугышлы уены.**

Әлбәттә, аулак өйләр җырлы-биюле уеннарсыз үтмәгән. Иң хөрмәтле кеше гармунчы егет саналган. Аның урыны түрдән булган. **“Наза”, “Сигезле” уены, “Кеше җыеш яки “Марш” уены, “Их, юдерләр итә**” көенә **“Мунча кертеш**” уеннары яратылып уйналган.

**Мунча кертеш уены**

Уенчылар парлап басалар. Парсыз калган уенчыны уртага чыгаралар. Аңа атап, беренче пар кулга-кул тотынып, такмак әйтә. Такмак әйтелеп беткәч, уртадагы уенчы үзенә беренче пардан пар сайлап ала (парлары белән алышыналар), аның белән уртада бииләр. Парсыз калучы уртага чыга, аңа икенче пар такмак әйтә. Уен шулай дәвам итә.

**Сигезле уены**

Уенчылар ике рәткә бүленеп кара-каршы басалар. Парсыз калган кеше, сигезле ясап, гармун көенә бии-бии, уенчыларны әйләнә. Гармун туктагач,

кем янында туктаса, шуның белән парлап бииләр. Уенны парсыз калган уенчы дәвам итә.

**Түбәтәйле уены.**



Балалар түгәрәкләнеп басалар. Түбәндәге җырны җырлый-җырлый, түбәтәйне бер-берсенә бирәләр:

Түбәтәеңне кигәнсең,
Бик ерактан килгәнсең,
Төскә матурлыгың белән
Шаккатырыйм, дигәнсең.

Кушымта:

Түп-түп-түбәтәй,
Түбәтәең укалы.
Чиккән матур түбәтәең
Менә кемдә тукталды.

Җыр ахырында түбәтәй кемдә калса, шуңа җәза бирелә (бии, җырлый, этәч булып кычкыра һ.б) Уен шулай дәвам итә.

**Наза уены**



Уенчылар парлашып бер сызыкка тезеләләр. Парсыз калучыга уенчылар, бию хәрәкәтләре ясап, такмак әйтәләр. Такмакның соңында ул үзенә пар алып, артка күчә. Парсыз калган кеше алга чыгып баса, уен шулай дәвам итә.

**Челтәр элдем читәнгә (җырлы –биюле уен)**

1. Егетләр бер рәткә, кызлар аларга каршы басалар. Кара-каршы җырлыйлар.
2. *Егетләр:*
3. Ал алъяпкыч челтәрле, илдә матур бетәрме?
4. Илдә матурлар бетәрме, җан сөйгәнгә җитәрме?
5. *Кызлар:*
6. Челтәр элдем читәнгә, җилфер-җилфер итәргә.
7. *Егетләр:*
8. Без килмәдек буш китәргә, килдек алып китәргә.
9. *Кызлар:*

10. Алын алырсыз микән, гөлен алырсыз микән?
11. Урталарга чыгып сайлап, кемне алырсыз микән?
12. *Егетләр:*
13. Алларын да алырбыз, гөлләрен дә алырбыз,
14. Күңелебезгә кем ошаса, шуны сайлап алырбыз.

Соңыдан һәр егет үзенә ошаган кызны алып, парлап биюгә чакыра.

Шулай итеп, “Аулак өйләр” һәрчак уен-көлке, җыр-бию белән гөрләп торган. Күңелләрдә аламалыкка,тәртипсезлеккә, әхлаксызлыкка , ямьсез уй-фикерләргә урын да, вакыт та калмаган.

# Йомгаклау

Шулай итеп, без уен дигәннән кешелек җәмгыятенең үсеш дәверендә хезмәт формаларын чагылдыру рәвешендә барлыкка килгән, яшь буынны физик һәм әхлакый, эстетик яктан тәрбияләү вазыйфасын һәм шулай ук олылар өчен күңел ачу, вакыт үткәрү һәм көнкүрештә берәр эш-шөгыльне, йоланы үтәү вазыйфасын башкаручы мавыктыргыч чаралар системасын аңлыйбыз.

Уеннар борын-борыннан халыкның көнкүреше, хезмәт формаларын чагылдыру нигезендә барлыкка килгән иҗат җимеше булганлыктан, анда милләтнең әүвәлдән килгән милли традицияләре, тормыш рәвеше, милли характеры ачык чагылыш таба. Уеннарның эчтәлегендә, образларында сакланып калган аерым элементлар, мотивлар татар халкының этнографиясен өйрәнү өчен дә кыйммәтле чыганак булып торалар.

Башкорт халкының уеннары һәм уен фольклоры милләтебезнең эстетик карашларын, милли характерын, генетик тамырларын ачыграк төсмерләргә дә мөмкинлек бирә. Аларда халыкның бөек рухы, иҗат куәте, иҗат мөмкинлекләре ачык чагыла. Икенче яктан ул халыкның рухи тормышын, көнкүрешен матурлык кануннары нигезендә оештыруның мөһим чаралары да булып тора. Кыскасы, уен ул – җитди шөгыль.

Гомүмән, хәзер халык уеннарының актив кулланыштант китүе ачык күренә.Әгәр дә без ата-бабаларыбыздан килгән шушы уеннарны, йолаларны, бәйрәмнәрне югалтмыйк, торгызыйк, саклыйк һәм үзебездән соңгы буынга тапшырыйк дисәк, күңелендә аз гына милли хис йөрткән һәр кеше бу изге эшкә карата битарафлык күрсәтергә тиеш түгел.

Күреүбезчә, югарыда күрсәтелгән проблема бик актуаль.Бу проблеманы күтәреп чыгу, шушындый темаларга кагылышлы Республика күләмендә фестиваль-конкурслар оештыру, тикшерү эшләре тәкдим итү бик урынлы һәм кирәкле дип уйлыйбыз.

# Файдаланылган әдәбият .


1. Алдырханова Э.Р. Әбием сондыгы, милли бәйрәмнәр, йолалар үткәрү өчен сценарийлар Уфа, 2008
2. Абсаликова Ф.Ш. Игры и развлечения зимнего периода у башкир в конце XIX — первой половине XX в. //Этносы и культуры на стыке Азии и Европы. Уфа, 2000.
3. Башкорт халык иҗады. Йола фольклоры.1том.Уфа,1995.
4. Башкирская энцеклопедия. Ф.Ф.Фатихова.
5. Биишева З. Произведения. В пяти томах. Первый том.- Уфа: Издательство "Китап", 1995.
6. Галяутдинова И.Г. Башкорт халык, балалар уеннары. Уфа.,2002
7. Галяутдинова И.Г. ,Ураксина Р.М. Балалар фольклоры: Мөгҗизәле, әкиятле балачак уеннарда калачак.Уфа,1996
8. Гөбәйдуллина Ф.Х. Башкорт халык йола бәйрәмнәре.Уфа,2011
9. Нагаева Л.И. Башкирские народные праздники, обряды и обычаи. – Уфа: Китап, 1999 – 160с.
10. Сөйләйманов Ә.М. Бала чаганың уен фольклоры. Уфа,2007


Башҡортостан Республикасы Мәгариф Министрлыгы

балаларга өстәмә белем бирү муниципаль бюджет
учреждениясы Уфа районы балалар иҗат йорты

# Тикшеренү эше

## *Уен-көлке,җыр- биюле*
## *“Аулак өй”*

Эшне башкарды:
«Дуслык» фольклор студиясы.
Җитәкчесе:
Гиндуллина Гөлфинә Нуррахман кызы
югары квалификациялы педагог.

Уфа -2016